**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 26.06.2020 № 506

**Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 28 сентябрендәге 2102 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

РФ Шәһәр төзелеше кодексы, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законнар, РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 09 июнендәге 363 нче номерлы «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында» карары нигезендә һәм административ регламентны Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, **КАРАР БИРӘ:**

1. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләрне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 28 сентябрендәге 2102 номерлы карары (2019 елның 27 маендагы 764 номерлы карар редакциясендә) белән расланган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләрне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.2. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Муниципаль хезмәт алучылар: дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, мәгълүмат системасы мәгълүматларын алу белән кызыксынган физик яисә юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).»;

2) 2.10 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Мәгълүмат системасындагы белешмәләр Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар (органнар) соратулары буенча күчемсез мөлкәт объектларын исәпкә алу, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне исәпкә алу буенча, ә федераль законнарда каралган очракларда физик һәм юридик затлар соратулары буенча түләүсез бирелә.»;

3) 3 нче бүлекнең 3.6., 3.6.1.-3.6.3 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

3.6.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеге тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында гариза бирүчегә мәгълүмат җиткерү;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар булдыру һәм җибәрү, шул исәптән комплекслы ведомствоара сорату буенча;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә кулланылган мөрәҗәгать итүченең көчәйтелгән квалификация цифрлы электрон имзасының дөреслеген тикшерү;

5) Башкарма комитетка документлар белән гариза җибәрү;

6) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

3.6.2. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат җиткерү

Гариза бирүче муниципаль хезмәтне алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен КФҮкә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча хәбәр итә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны КФҮ сайтыннан http://mfc16.tatarstan.ru/ ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документациянең составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

3.6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.6.3.1. Гариза бирүче шәхсән, ышанычлы зат аша яисә электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү турында язма гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә КФҮгә, КФҮнең читтә урнашкан эш урынына документлар тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон рәвештә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре Порталы аша җибәрелә. Электрон рәвештә кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.6.3.2. КФҮ белгече, гаризаларны кабул итүне алып баручы, КФҮ эше регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар КФҮ эше регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.6.4. Документлар пакетын формалаштыру

3.6.4.1. КФҮ белгече КФҮ эш регламенты нигезендә:

муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә кулланылган мөрәҗәгать итүченең көчәйтелгән квалификация цифрлы электрон имзасының дөреслеген тикшерә;

ведомствоара соратуларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга, шул исәптән комплексլы ведомствоара сорату буенча формалаштыра һәм җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар КФҮ эше регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: җибәрелгән соратулар.

3.6.4.2. КФҮ белгече соратуларга җаваплар алганнан соң документлар пакетын формалаштыра һәм аны башкарма комитетка КФҮ эше регламентында билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар КФҮ эше регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Башкарма комитетка җибәрелгән документлар.

3.6.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен тапшыру

3.6.5.1. Башкарма комитеттан муниципаль хезмәт нәтиҗәсе килгәндә, КФҮ белгече аны билгеләнгән тәртиптә терки. Гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында гариза бирүчегә (аның

вәкиленә) хәбәр итә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар Башкарма комитеттан документлар кергән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) хәбәр итү.

3.6.5.2. КФҮ белгече мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирә

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне КФҮ эше регламентында билгеләнгән срокларда чират тәртибендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Интернет челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтына http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин